

Татар Пешлә авылында яшәvче Хәсән кызы Шәфика Кильмаевага (Ларина) 31нче март конне 95 яшь тула.
1924нче елда Татар Пешлә авылында ишле гаиләдә беренче бала булып Шәфика Хәсән кызы туа. Гаиләдә барлыгы тугыз бала була. Ул авыл мәктәбендә жиде ел укып чыга.
Сугыш башлану турындагы хәбәр Шәфика әбием-не кайгыга сала. Аны гына тvгел, ә барлык совет халкын. Ана ул вакытта барлыгы 17 яшь була. Әтисен сугышка алалар, әнисе кулында 9 бала кала, шуна кvрә әбием эшләргә мәжбvр була. Бер сvз белән әйткәндә, әнисенен булышчысы була.       Башта туган колхозында эшли. Аннары  шул ук 1941нче елны алты ай буе Орехово-Зуево шәһәре янындагы торф эшләрендә хезмәт итә. Торф чыгарып, аннары аны киптереп завод мичләрен ягу очен тапшыралар. Шушы эшләрдән сон, Шәфика әбиемне башка кызлар белән Большие Березники дигән якка окоплар казырга озаталар. Сура якларында урман актаралар; кызлар кул пычкысы (пила) белән урман кисәләр һәм агачларны платформага тоиләр.
1942нче ел. Әбием Куйбышев тимер юлына штат эшчесе булып урнаша. Проводниклар курсларын укып чыккач, пригород поездында эшли башлый. Маляр (буяучы) булып та эшләргә туры килә ана. Шулай итеп, дәхшәтле сугыш еллары кайда гына илтеп кайтармый әбиемне.
Сугыш вакытында  авыр эшләр эшләгән  очен Хәсән кызы Шәфика медаль – орденнар белән бvләкләнә: Орден за отличную работу (1943нче ел), медаль «За доблесный труд во время ВОВ», берничә Юбилей медале, алар арасында «Жинvгә 70 ел» дигән медале дә бар. Россия президенты В.В.Путиннан  һәр ел котлауларын алгач, ул бик тә шатлана.
Шәфика әбиемнен дә гаиләсе бар: улы - Ринат, килене - Галия һәм ике оныгы, оныкасы (правнугы), кайсылар аны бик кадерләп карыйлар, яраталар һәм дә горурланалар анын белән.
Без, анын туганнары, саулык-сәламәтлек, озын гомер, жан тынычлыгы һәм якты коннәр телибез. Тормыш юлын һәрчак балкып торсын. Ягымлы, шат булсын кvнелен. Озын гомер, бәхет-шатлык белән бер кайгысыз vтсен гомерен.

**Оныгын Юлия**